# География

# 6 нчы класс

***Әлки муниципаль районы Алпар гомуми урта белем бирү мәктәбе география укытучысы Сафиуллина Фәниянең дәрес эшкәртмәсе***



# Дәреснең темасы: Җил. Анын барлыкка килү сәбәпләре.

## *Дәреснең максаты:*

***1.Җилләр барлыкка килүнең сәбәпләрен ачыклау. ”Бриз”,”Муссон” төшенчәләре формалаштыру. Укучыларны “җилләр розасы” төзергә өйрәтү.***
***2.Җилләр турында алдагы сыйныфларда алынган белемнәрне ныгыту. Карта белән эшләү күнекмәләрен ныгыту.***
***3.Җилләрнең табигатьтәге һәм кеше тормышындагы әһәмиятен ачыклау, җил көчен куллануга укучыларда кызыксыну хисе тәрбияләү. Укучыларның сөйләм телен үстерү.***



**Дәреснең тибы:** ***Яңа белемнәр үзләштерү.***

**Дәреснең төре:** ***шигыри дәрес.***

**Җиhазлау:** ***Дөньяның физик картасы, “җилләр розасы “ графигы, карточка (географик диктант),”йолдызчык” уены(тест),дәреслек, рәсемнәр, термометр макетлары,магнитофон, барометр.***

# Дәрес барышы:



**I.Оештыру өлеше(1-2мин.)**
Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.Дежур укучы отчетын тыңлау.
**Дежур отчеты**:
Бүген мартның унбере
атнаның пәнҗешәмбе көне.
Җил көньяк-көнбатыштан исә,
әчесе бераз битне кисә.
Һава түгел салкын
температура -12гә якын.
**Укытучы:**
укучылар бүген безнең дәрестә
“Җилләр” темасы
хәзер без сезнең белән
ачыкларбыз күп нәрсәне:
җилләрнең барлыкка килү сәбәбен,
“Бриз”,”Муссон”төшенчәләрен,
җилнең әһәмиятен
һәм аның төрле сыйфатын.
(Укучыларга диңгез рәсеме таратыла.)



## II.Актуальләштерү(7-8 мин)



Ә хәзер әйдәгез

Хәтерне яңартыйк,

Үткәннәрне кабатлыйк.

Эшләтик әле бераз башны

Исәплик уртача температураны

Ачыклыйк еллык амплитуданы,

Бу үзгәрешләрнең сәбәпчесе кояшмы.

Шуларны ачыклар өчен

Куеп бөтенебез бар көчен

“Йолдызлар” уенын уйнап



Карыйк әле үзебезне сынап.

Һәр дөрес җавабыгызга

Әләгер бирәр кораб.

(Укучыларга йолдызчыклар таратыла, андагы тест сорауларына җавап бирелә.)

Йолдызчыктагы тест сораулары:

1.Тәүлек дәвамындагы иң югары һәм иң түбән t арасындагы аерымлык.

а) t тирбәнешләренең тәүлеклек амплитудасы дип атала. (+)

б)уртача тәүлеклек t дип атала.

в)уртача айлык t дип атала.

2.Җир өслегенә һәм андагы предметларга һаваның басым көче?

а)атмосфера басымы (+)

б)кан басымы

в)нормаль атмосфера басымы.

3.нормаль атмосфера басымы?

а) 760 мм (+)

б)740 мм

в)780 мм

4.Һава басымын үлчәү приборы?

а)барометр (+)

б)термометр

в)градусник

5.Ел дәвамында җылылык күләменең үзгәреше нәрсәгә бәйле?

а)кояшка (+)

б)көн озынлыгына

в)йолдызларга

6.Уртача тәлеклек t лар суммасын айдагы тәүлекләр санына бүлеп

а)уртача айлык t ны (+)

б) t тирбәнешләренең еллык амплитудасын

в)уртача тәүлеклек t ны .

2.Термометр макетлары ярдәмендә тәүлеклек амплитуданы ачыклау.
(бер-ике мисал кітерү һәм укучыларның һәр дөрес җавабына берәр кораб рәсеме бирү.Укучылар корабларын диңгез рәсеменә ябыштыра баралар).

3.Географик диктант.(укучыларга карточкалар бирелә,эш тәмамлангач бер-берсенең эшләрен алып тактадагы дөрес җаваплар буенча эш тикшерелә)

Географик диктант.

а) һава температурасын үлчәү приборы-........ .

б) ел дәвамында җылылык күләме үзгәреше........ бәйле.

в) тәүлек дәвамында иң югары һәм иң түбән температура арасындагы аерымлык-.......... .

г) һава басымын үлчәү приборы-........ .

д)нормаль атмосфера басымы-....... .

е) елның иң җылы аендагы уртача температура белән иң салкын аендагы температура арасындагы аерымлык-......... .

(Тактадагы дөрес җаваплар:а-темометр,б-кояшка,в-тәүлеклек амплитуда,г-барометр,д-760 мм,е-еллык амплитуда.)

## III Яңа белемнәр үзләштерүгә кереш.( 5-6 мин.)



Әйдәгез әле укучылар
башны эшкә җигик
бераз табышмаклар чишик.

1.Аяксыз, кулсыз
агач сындыра. (Җил)
2.Канатсыз булсада җырлый-җырлый оча
үткән-барганны коча.
Берәүләргә каршы төшә,
икенчеләрен куып китә. (Җил)

Әйе,җил .Без бүгенге дәресебездә җил турында сөйләшербез дә инде.Дәфтәрләрне ачып,число,теманы язабыз һәм бераз сөйләшеп алабыз.

-Нәрсә ул җил? Һаваның җир өстендә хәрәкәте җил дип атала

-Җил нинди юнәлештә хәрәкәт итә? Җил горизонталь рәвештә төрле юнәлешләрдә хәрәкәт итә.

-Җилнең тизлеге буламы? Әйе,җилнең тизлеге була.Тизлеге зуррак булган саен ул көчлерәк була.

## Яңа белемнәр үзләштерү. (20-25 мин.)

**1.Җил.**

Әйе,укучылар җилләр төрле була,көчле,көчсез.Җирнең һава тышчасының аскы өлеше бик сирәк тынычсыз була,һава массалары һәрвакыт хәрәкәт итеп тора һәм җилләр барлыкка килә.

Һаваның горизонталь юнәлештәге хәрәкәте җил дип атала.(кагыйдә дәфтәрләргә языла.)

Менә шушы җил рәвешендә генә без үтә күренмәле,иссез.төссез һаваның хәрәкәтен тоябыз.Ә хәзер җил турында бер шигырь тыңлап алыйк әле.

Котырды җил,котырды
Агачларны сындырды,
Түбәләрне кубарып
Әллә кая тондырды.
Күзне ачсаң чүп атты,
Бүрекне алып чапты.
Оясында йоклаган
Каргаларн уятты.
Бөтен дөнья шаулады
Өйләр чак-чак аумады.
Ләкин хулиган җилне
Беркем тыя алмады.



**2. Җилнең сыйфатлары**.

Ә сез укучылар җилләр турында нәрсәләр беләсез,җилләрне ничек сыйфатлап була? (1-2 укучыны тыңлау)

Салкын,көчле,шаян,шук,куркыныч, әкрен һ.б

Ярый укучылар .җилнең сыйфатлары турында күп беләсез икән.Бик әйбәт.

**3. Бриз,муссон төшенчәләре**.(Тактага бриз барлыкка килү рәсеме эленә.)

Җил барлыкка килүнең төп сәбәбе җир өслегенең төрле урыннарында атмосфера басымының төрлечә булуыннан гыйбарәт.Ә басым ни өчен төрлечә була соң? Без моны диңгез ярында барлыкка килгән,бриз дип аталган җил мисалында карап үтик. Коры җир көндез тизрәк,су озаграк җылына. Җирдән җылы алган һава киңәя,1-2 км биеклеккә күтәрелә дә тирә якка тарала.Шуның өчен коры җир өстендә басым төшә ә килгән әлеге һава агымыннан су өстендә басым күтәрелә.Су өстендәге салкынча тыгыз һава басым кимрәк булган урынга, ягъни коры җиргә юнәлә. Көндезге бриз шулай барлыкка килә(төнге бриз киресенчә)

Басым арасында аерма никадәр зур булса,җил шул кадәр көчлерәк була.

Бриз- судан коры җиргә, коры җирдән суга таба исүче,тәүлек дәвамында үзенең юнәлешен үзгәртүче җил.(кагыйдә дәфтәрләргә яздырыла)

Дәреслектәге 76 нчы рәсемгә анализ.

| | |
|---|---|
| -Көндезге бриз кая таба исә? | Коры җиргә,һава басымы кимрәк булган урынга. |
| -Коры җиргә таба искәнен каян белеп була? | 1)коры җирдә басым түбән,су өстендә югары |

2) яр кырыендагы флагтан.

3)көймәдәге флагтан.

4)җир өстендә t җылырак,ә су өстендә t түбән.

Укучылар ә хәзер төнге бриз формалашуны кем аңлата алыр.(1 укучы схема буенча төнге бриз формалашуны аңлата.)

**4. Муссон**. (Тактага карта эленә)

Кышын коры җирдән диңгезгә исә
җилнең муссон дигәне.
Җәен инде киресенчә
Диңгездән коры җиргә исә.

Муссоннар-алар бризга охшаган җилләр,тик алар бриздан аермалы буларак ел дәвамында үзләренең юнәлеәен үзгәртәләр.

Дәреслектәге 77 нче рәсемгә анализ.

Муссон турында язма уку.

“бик борынгы заманнарда,әле диңгез,океаннарда җилкәнле көймәләр, кораблар гына йөзгән вакытта бик күп гарәпләр июнь-июль аеларында әкияттәгедәй бай һиндстанга юл тотканнар.Бу вакытта көньяк-көнбатыш җил корабларның җилкәннәрен киергән һәм алар көньяк гарәпстаннан һиндстан ярымутравына хәтле булган барлык юлны бик тиз үткәннәр.Кыш аеларында кораблар товар төяп кайтыр юлга чыкканнар һәм тагында юлдаш җил аларның корабларын куып алып кайткан,чөнки бу вакытта җил үзенең юнәлешен үзгәрткән була.Диңгезчеләргә шулай булышкан җилләргә гарәпләр маусин дип әйтәләр, бу ел вакыты, сезонлы дигәнне аңлата.Һәм җилгә бик төгәл дә исем бирелгән.

Чөнки муссон үзенең юнәлешен елына 2 тапкыр үзгәртә.Шактый вакытлар үткәч гарәпләрнең маусин сүзен французлар үзләренчәрәк үзгәртәләр һәм бу җил муссон дип атала башлый.(муссон кагыйдәсен тактага элү һәм дәфтәрләргә яздыру.)

Физкультминут

(күзләргә ял,гәүдәне хәрәкәтләндерү)

**5. Җилнең әһәмияте**.

-Ә хәзер җилнең әһәмияте трында сөйләшеп алыйк.

-Кеше җил көченнән файдаланамы? Әйе,кешеләр җил көченнән борынгы заманук файдаланган.

-Җил көченнән ничек файдаланганнар? Җил тегерməннәре төзегәннәр,җилкәнле судно,кораблардан файдаланганнар.

-Җилдән хәзер файдаланалармы? Хәзер җил двигательләре ясап электр тогы алалар.


-Җилнең зарары бармы? Җил төрле бәлә-казага сәбәпче булырга мөмкин.Коры җирдәге давыллар зур җимерүләр китерә,ә диңгездәгесе суднолар өчен куркыныч тудыра.

Әйе, укучылар җилнең файдасы да, зарары да бар. Җил көченнән файдалану яки саклану өчен аның юнәлешен,тизлеген алдан белеп торырга кирәк.

**6. Җилнең юнәлеше һәм көче.**


Белер өчен җилнең юнәлешен
Билгеләр өчен аның көчен,
Кешеләр барын заманнан
Җирле билгеләргә караган.
Океандагы суга караган,
Коры җирдә агач тирбәлүен,
Торбадан чыккан төтеннең
Авышлыгын да сынаган.
Бу билгеләрне истә тотып
Махсус шкала раслаган.
Җилнең тизлеген сек/метрларда
Ә көчен балларда санаган.
Штиль диләр җилсез көнне
Гарасат диләр куркыныч җилне.
Бар тагы өермәсе, тайфуны
Беләсез инде сез аларны.
Борынгы Рим сәүдәгәре Гиппал
Өйрәнә муссон хәрәкәтен.
Балларда үлчәргә җил көчен
Әйтә Боффоот исемле адмирал.







**Дәреслекнең 2 нче форзацына анализ ясау.**



ФЛЮГЕР.

Җилнең юнәлешен флюгер ярдәмендә билгелиләр. Флюгерның угы үзе беркетелгән күчәрдә иркен әйләнә ала һәм аның очлы ягы һәрвакыт җилгә каршы юнәлә. Уктан астарак кузгалмый торган сигез металл таякчык беркетелә, алар горизонтның төп һәм ара якларын күрсәтәләр. Флюгер угыннан өстәрәк күчелгән рам да ук белән бергә әйләнә. Бу рамга югары очыннан гына беркетелгән металл пластинка эленгән. Җил көчлерәк исcә, пластинка үзенең вертикаль торышыннан күбрәк авыша.

җил көчен үлчәү өчен барометр дигән прибор,
ә юнәлешен белү өчен флюгер куллана-
лар.(укучыларга флюгер төзелешен тас-
вирлап язган язма таратыла.)




**7.Җилләр розасы.**

Теләсә кайсы торак пунктның искән җилләре юнәлешен күрсәткән диаграмма җилләр розасы дип атала.Диаграмма бер ноктадан горизонт румблары юнәлешендә сызылган нурлардан гыйбарәт.(Дәреслектәге 79 нчы рәсемгә анализ.)

**8.Румб якларының халыкара исеме.**(Тактага таблица эленә һәм кыскача аңлатма бирелә.)

| Хәрефле билгеләре | | Румбның исеме. |
|---|---|---|
| Татарча | Халыкара | |
| Т. | N | Төньяк (норд) |
| Т.кч. | NE | Төньяк-көнчыгыш. (норд-ост) |
| Кч. | E | Көнчыгыш. (ост) |
| К.кч. | SE | Көняк-көнчыгыш. (зюйд-ост) |
| К. | S | Көньяк. (зюйд) |
| К.кб. | SW | Көньяк-көнбатыш (зюйд-вест) |
| Кб. | W | Көнбатыш (вест) |
| Т.кб | NW | Төньяк.кб (норд-вест) |



**Ү.Алынган белемнәрне ныгыту.(5-7 мин.)**

1.Болытлар.(Магнитофонда талгын музыка,җил тавышы.)

Укучылар магнитафоннан җил тавышын тыңлаганда бездә дә җилләр искән һәм үзләре белән серле болытлар алып килгән. Әйдәгез әле ул болытларны ачып карыйк.(Һәр укучы тәртип буенча бер болытта язылган җилгә тасвирлама бирә.Бриз,муссон,өермә,торнадо,гарасат,тайфун.)




2.Җилләр розасы төзү.(күзәтү көндәлекләре буенча)

3.Сүзлек өстендә эш.(сүзлек дәфтәрләренә языла)

Бриз-француз сүзе җиңелчә җил дигән сүз.

Муссон-гарәпчәдән тәрҗемәсе-сезон,фасыл.

Флюгер-голландчадан канатлы дигән сүз.

4.Өстәмә материал”Торнадо”(вакыт калса)

**ҮI.Өй эше**

1.Дәреслектәге җил темасын укырга.

2. 4нче сорау язмача.

**ҮII.Йомгаклау.**

Дәрескә йомгак ясау,билгеләр кую.

# МОЛОДЦЫ!

